Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авылҗирлеге составына керүче Саескан Тавы авылы, Кама поселогы
торак пунктларында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ  КАРАРЫ

2019  елның 31 октябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының  35 маддәсе нигезендә,Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Саескан Тавы авылы, Кама поселогы  торак пунктларында гражданнар җыены  **КАРАР БИРӘ**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль  районы  Олы Елга  авыл җирлеге составына керүче Саескан Тавы авылы, Кама поселогы торак пунктларында  тору урыны буенча  теркәлгән  балигъ  булган  һәр кешесеннән, уку йортларына йөреп (көндезге бүлектә) укучы студентлардан һәм 1 төркем инвалидлардан  гайре,  500 сум күләмендә үзара салым  акчасы кертергә.
2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

   -янгын сүндерү гидрантлары сатып алуга һәм аларны Олы Елга, Казаклар авылларына урнаштыруга;
   - Олы Елга, Казаклар, Сорочьи Горы авылларындагы су этем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алуга;
   - авыл җирлеге торак пунктларында урам яктырткычлары өчен  энергия саклаучы лампалар сатып алуга һәм алыштыруга;
   - Олы Елга авылының Яшьләр, Күл, Мәктәп, Нариман, Совет, Чишмә, Яңа-2, Мөхәммәтгали урамнарындагы юлларны ремонтлауга;
   - кышын авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның йөри торган өлешләрен карап торуга (кардан  арындыруга);
   - Олы Елга авылының Яшьләр  урамында  “Бизнә” инеше аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлауга.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы  Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25  йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Саескан Тавы авылы,Үзәк урам,16А йорт; Кама поселогы, Курорт-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4.Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Садриев